**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кармәт авыл җирлеге башкарма комитеты**

**КАРАР**

**№ 7** **14 март 2016 ел**

**Хөкем ителгәннәрнең җәзасын үтәү өчен объектлар һәм мәҗбүри эш төрләрен билгеләү турында**

РФ Җинаять кодексы нигезендә 49 статьясының 1 өлеше, 25 статьясының 1 өлеше нигезендә. РФ Җинаять башкарма кодексының хөкем ителгәннәр Иске Кармәт авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри эшләр рәвешендә җәзаны үтәгәндә, шулай ук мәҗбүри эшләр рәвешендә җинаять җәзасы билгеләнгән затларны төзәтү, аларның җәмгыять нормаларына, кагыйдәләренә, иҗтимагый-файдалы хезмәткә хөрмәтле мөнәсәбәтен формалаштыру максатларында Иске Кармәт авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Иске Кармәт авыл җирлеге территориясе чикләрендә мәҗбүри эшләрне башкару урыннарын билгеләргә: Иске Киремет авылы җинаять – башкару инспекциясе белән килешү буенча.

2. Мәҗбүри эш төрләрен билгеләргә - торак пунктларны төзекләндерү һәм яшелләндерү, зиратларны төзекләндерү, юллар һәм буалар буендагы куакларны кисү, елгалар һәм чишмәләр территорияләрен санитар чистарту, җинаять-башкару инспекцияләре белән килешү буенча юлларны һәм башка тышкы төзекләндерү объектларын ремонтлау.

3. Әлеге карарны Аксубай районы буенча ФКУ филиалы белән берлектә Россия Федераль җәзаларны үтәтү хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Идарәсе җинаять-башкару инспекциясе тарафыннан Иске Кирәмәт авыл җирлеге территориясендә яшәүче мәҗбүри эшләргә хөкем ителгән затларга карата суд хөкемнәрен үтәүне тәэмин итү өчен җибәрергә.

4. «Мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәзаларга хөкем ителгән затларны үтәү өчен мәҗбүри эш төрләрен раслау турында» 2016 елның 24 февралендәге 6 номерлы карары үз көчен югалткан дип саналырга тиеш.

5. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында урнаштырырга: http:// aksubayevo.tatarstan.ru.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Иске Кармәт авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Ф.З.Мусабиков